УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАРҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең кешеләр гомере һәм мөлкәте өчен иминлекне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча буенча Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 03.07.2015 № 01-05/112-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе

Административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең кешеләр гомере һәм мөлкәте өчен иминлекне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча буенча Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 03.07.2015 № 01-05/112-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 09.06.2016 № 01-05/154-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Идарә тарафыннан дәүләт вазыйфасын башкару түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе («Российская газета», № 237, 1993 ел, 25 декабрь) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Граждан кодексы, (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, ст. 3301) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, 2001 елның 30 декабре № 195-ФЗ (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2002, № 1, ст. 1) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге № 196-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 196-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 1995, № 50, ст.4873) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге № 184-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 184-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2002, № 52, ст.5140) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2006, № 19, ст. 2060) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2008, № 52, ст.6249) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» Россия Федерациясе Министрлар Советының – Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге № 1291 карары белән расланган Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә («Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы» 20.12.1993 № 51, ст. 4943) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарга һәм башка төрдәге техникага паспортлар кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 15 маендагы № 460 карары (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 22.05.1995, № 21, ст.1969) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге № 489 карары белән расланган Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын дәүләт күзәтчелеге органнары һәм муниципаль тикшереп тору органнары тарафыннан әзерләү кагыйдәләре (алга таба – № 489 РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2010, № 28, ст.3706) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Техник торышларына дәүләт күзәтчелеген башкаручы органнар тарафыннан теркәлгән үзйөрешле машиналарны һәм башка төрдәге техниканы техник карап чыгу турында» 2013 елның 13 ноябрендәге № 1013 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2013, № 47, ст.6099);

«Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге № 415 карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2015, № 19, ст. 2825) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Мәҗбүри таләпләрне бозуны булдырмау турындагы кисәтү, шундый кисәтүгә карата юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан каршылыклар бирү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итүне төзү һәм җибәрү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге № 166 карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, (бастыру номеры 0001201702140002);

Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә шушы документлар һәм (яисә) мәгълүмат үз карамакларында булган дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында соратып алынучы документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеген раслау турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге № 724-р күрсәтмәсе (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 2016, № 18, ст. 2647) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан 16.01.1995 расланган Тракторларны, үзйөрешле юллар салу машиналарын һәм бүтән машиналарны һәм аларга тагылмаларын Россия Федерациясендә тракторларның, үзйөрешле юллар салу машиналарының һәм бүтән машиналарның һәм аларга тагылмаларының техник торышына дәүләт күзәтчелеге органнары тарафыннан дәүләт теркәве кагыйдәләре («Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене» 1995, № 5) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге № 141 боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) («Российская газета», 2009, 14 май, № 85) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Нефть продуктларын саклаганда, транспортлаганда һәм реализацияләгәндә хезмәтне саклау кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 2015 елның 16 ноябрендәге № 873н боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 3 февраль, бастыру номеры: 0001201602030003;

Дәүләт тармак стандартлары:

ГОСТ 12.2. 007.0-75 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Иминлекнең гомуми стандартлары». СССР Дәүләт стандартлар комитетының 10.09.1975, № 2368 боерыгы белән расланган (М.: ИПК Издательство стандартов, 2001);

ГОСТ 12.1.030-81 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Иминлекнең гомуми стандартлары. Электр иминлеге. Яклау буенча җиргә тоташтыру. Нульләштерү» СССР Дәүләт стандартлар комитетының 15.05.1981 № 2404 карары белән расланган;

ГОСТ 1510-84. «Нефть һәм нефть продуктлары. Маркировкалау, төргәкләү, транспортлау һәм саклау» СССР Дәүләт стандартлар комитетының 07.08.1984 № 2776 карары белән расланган;

ГОСТ 12.2.003-91 «Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Җитештерү җайланмалары. Иминлекнең гомуми таләпләре» Продукция

сыйфатына һәм стандартларына идарә буенча СССР Дәүләт стандартлар комитетының 06.06.1991 № 807 карары белән расланган (М.: Издательство стандартов, 1991);

ГОСТ Р 50911-96 «Авыл хуҗалыгы техникасы. Ремонт-технологик җайланмалар. Иминлекнең гомуми таләпләре» Россия Госстандартының 06.06.1996 № 354 карары белән кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән (М.: ИПК Издательство стандартов, 1996);

ГОСТ 7463-2003 «Тракторлар һәм авыл хуҗалыгы машиналары өчен пневматик шиналар» Стандартлаштыру, метрологияләү һәм сертификацияләү буенча Дәүләтара Совет тарафыннан расланган (МГС) (М.: ИПК Издательство стандартов, 2004);

ГОСТ Р 53489-2009 ССБТ «Элмәле һәм тагылмалы авыл хуҗалыгы машиналары. Иминлекнең гомуми таләпләре» Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 10.12.2009 № 678-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2010);

ГОСТ 7751-2009 «Авыл хуҗалыгында кулланылучы техника. Саклау кагыйдәләре» Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 04.03.2011 № 27-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2011);

ГОСТ 12.2.042-2013 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Терлекчелек һәм терлек азыгы җитештерү өчен машиналар һәм технологик җайланмалар. Иминлекнең гомуми таләпләре» Росстандартның 08.11.2013 № 1381-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2014);

ГОСТ 12.0.004-2015 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Хезмәт иминлегенә өйрәтүне оештыру. Гомуми нигезләмәләр» Росстандартның 09.06.2016 № 600-ст боерыгы белән кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән (М.: Стандартинформ, 2016);

ГОСТ 12.4.026-2015 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Сигнал бирү төсләре, иминлек тамгалары һәм сигнал бүленешләре. Билгеләү һәм куллану кагыйдәләре. Гомуми техник таләпләре һәм характеристикалары. Сынаулар методлары» Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 10.06.2016 № 614-ст боерыгы белән кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән (М.: Стандартинформ, 2016);

«Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.12.2011 № 1064 карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы» 2012, № 9, ст.0321) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2012 № 1192 карары

(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы» 25.01.2013, № 7, ст.0194) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5.2 пунктчасының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта гына тикшерү уздырырга, күчмә тикшерүне – бары тик хезмәт таныклыгын, Идарә башлыгының тикшерү билгеләү турындагы боерыгы күчермәсен күрсәткәндә генә, гариза бирүченең канәгатьләндерелмәгән);»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.5 – 2.4.12 пунктлар өстәргә:

«2.4.5. Тикшерү уздыруны билгеләү турында Идарә башлыгы урынбасарын билгеләү мөмкин булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар һәм № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү уздыру турында прокуратура органы белән килештерелгән документ күчермәсе;»;

1.5.3 пунктчада:

өченче абзацта «һәм Россия Федерациясе законнарына туры килмәгән» сүзләрен «, шулай ук кулланышлары Россия Федерациясе законнары белән каралмаган норматив документлар таләпләрен үтәү» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик заттан, индивидуаль эшкуардан тикшерү датасына кадәр документларны, мәгълүматны тапшырттыру. Тикшерү уздыру турында Идарә тарафыннан боерык кабул ителгәннән соң ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.»;

2 бүлектә:

2.1 бүлекчәсенең 2.1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.7. Идарәнең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында, Идарә бүлекләрендәге мәгълүмат стендларында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

Идарәнең урнашкан җире, әлеге Административ регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән контакт телефоннары турында белешмәләр, Идарәнең, Идарә бүлекләренең электрон почтасы адреслары, Идарәнең рәсми сайты адресы турында белешмәләр;

хокук бозуларны профилактикалауның расланган еллык программасы;

үтәлүләрен бәяләү тикшереп тору предметы булган мәҗбүри таләпләре кергән норматив хокукый актлар яисә аларның өлешләре исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстлары;

мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган күрсәтмәләр турында белешмәләр, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эше турында белешмәләр, бүтән алымнар белән урнаштырылган бүтән мәгълүмат турында белешмәләр. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне билгеләүче яңа норматив хокукый актлар эчтәлеге, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе турында комментарийлар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә кертү һәм тәэмин итү өчен кирәкле оештыручаралары, техник чаралар уздыру турындагы рекомендацияләр урнаштырыла;

дәүләт вазыйфасын башкару практикасын дами рәвештә, елына кимендә бер мәртәбә үтәлә торган гомумиләштерү буенча белешмәләр, шул исәптән аеруча еш очрый торган мәҗбүри таләпләрне бозуларны күрсәтеп, мондый бозуларны булдырмау максатларында, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата рекомендацияләре белән;

әлеге Административ регламент (Идарә бинасының мәгълүмат стендында – әлеге Административ регламентның аерым фрагментлары);

планлы тикшерүләр уздыруның Идарә башлыгы боерыгы белән расланган еллык планы (алга таба – План);

дәүләт вазыйфасын башкару эшчәнлеген җайга салучы закон актларыннан һәм бүтән норматив хокукый актлардан өземтәләр;

машиналар һәм җайланмалар хуҗаларын Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан кабул итү режимы;

Идарәнең дәүләт вазыйфасын башкаручы баш дәүләт инженер-инспекторлары карарларына, гамәлләренә яисә гамәл кылмавына карата шикаять белдерү тәртибе;

дәүләт вазыйфасын башкаргандагы гамәлләрнең эзлеклелеген чагылдыручы блок-схема.»;

2.4 бүлекчәдә:

2.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез түбәндәгеләр була:

1) юридик затның, индивидуаль эшкуарның мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозу очракларын бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы узу;

2) Идарәнең вазыйфаи затының юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә генә, тикшереп тору чаралары нәтиҗәләрен анализлау, Идарәгә гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау яисә алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән тәкъдим итүе:

а) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү куркынычы барлыкка килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы туу;

б) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучылар хокукларын бозу турында хокуклары бозылган гражданнар Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче хокукларын яклау (торгызу) турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга мөрәҗәгать итеп тә, мондый мөрәҗәгать каралмаган йә Идарәгә мөрәҗәгать иткән затның таләпләре каралмаган булса, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турындагы белешмәләре булган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү өчен нигез булмаса. Мөрәҗәгатьтә яисә гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү өчен нигез була алган очракта, Идарәнең вазыйфаи заты аның мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның авторы кем булуына шиге булганда мөрәҗәгать итүче затны билгеләү өчен нигезле чара күрергә тиеш. Гариза бирүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар бары тик гариза бирүче аны мәҗбүри авторлаштыру, идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасында каралган мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып җибәрелгән булса гына, планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булырга мөмкин.

2.4.6. Әлеге Регламентның 2.4.3 пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны караганда элегрәк кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата тикшереп тору гамәлләре уздыру нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.4.7. Мәҗбүри таләпләрне бозган зат турында дөрес мәгълүмат, мәҗбүри таләпләрне бозуы турында белешмәләр йә әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләр җитәрлек булмаганда, Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи заты кергән мәгълүматны алдан тикшерү уздырырга мөмкин. Алдан тикшерү уздыру барышында гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу чаралары күрелә, юридик затның, индивидуаль эшкуарның Идарә карамагында булган документлары карала, кирәк чакта, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм әлеге затларга мәгълүмат бирү һәм Идарә таләпләрен үтәү бурычын йөкләмичә генә,

тикшереп тору чарлары гамәлгә ашырыла. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, индивидуаль эшкуардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар бирү соратып алынырга мөмкин, әмма мондый аңлатмаларны һәм бүтән документларны бирү мәҗбүри булмый.

2.4.8. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозган затлар, мәҗбүри таләпләрне бозу турында йә әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат алу ачыкланганда, Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи заты планнан тыш тикшерү билгеләү турында әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү хакында дәлилләнгән тәкъдим әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, индивидуаль эшкуарны җаваплылыкка тарту чаралары күрелми.

2.4.9. Алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү башлаганнан соң, тикшерүне оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгать яисә гариза анонимлыгы ачыкланса йә мөрәҗәгатьтә яисә гаризада күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр булуы ачыкланса, тиешле тикшерү Идарә башлыгы, Идарә башлыгы урынбасары карары буенча туктатыла.

2.4.10. Әгәр гаизаларда, мөрәҗәгатьләрдә күрәләтә ялган белешмәләр күрсәтелгән булса, Идарә гражданнан, шул исәптән юридик заттан, индивидуаль эшкуардан Идарәнең шушы затлардан кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карауга тотылган чыгымнарын түләттерү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.4.11. Идарәнең юридик затны, индивидуаль эшкуарны планнан тыш тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерүе турындагы гаризасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган рәвештә рәсмиләштерелә.

2.4.12. Планнан тыш тикшерү уздыру өчен юридик затның, индивидуаль эшкуарның мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуын бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлану нигез булган очракта, мондый тикшерү предметы Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан бирелгән үтәлеш кенә дә булырга мөмкин.»;

3 нче бүлектә:

1 нче таблицадагы «Мәҗбүри таләпне урнаштыра торган норматив хокукый акт» графасының 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ГОСТ 12.4.026-2015 (5, 6 бүлекләр)»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата белдерелә торган һәм үтәлеше мәҗбүри таләпләр урнаштыра торган норматив хокукый актлар белән тикшереп торыла, тикшергәндә юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата белдерелә торган мәҗбүри таләпләр исемлеге 1 нче таблицада китерелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2 – 3.15 пунктлар өстәргә:

«3.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Идарә әлеге мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау турында Административ регламентның 3.3 – 3.15 пунктлары нигезендә кисәтү бирә.

3.3. Идарә, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә генә, тикшереп тору чараларын гамәлгә ашырганда алынган йә кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган гаризалардан һәм мөрәҗәгатьләрдән гайре), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларынан алынган мәгълүматта әзерләнүче бозулар турында яисә мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеләре турында белешмәләре булганда, әгәр мәҗбүри таләпләрне бозу кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китергән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү турында расланган белешмәләр булмаган һәм юридик зат, индивидуаль эшкуар элегрәк тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган очракларда, Идарә юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне бозуны булдырмау турында кисәтү чыгара һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта Идарәгә мондый кисәтүдә күрсәтелгән срокта хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Кисәтүне җибәрү турындагы карарны Идарә башлыгы, Идарә башлыгы урынбасары яисә Идарә боерыгы белән билгеләнгән Идарәнең бүтән вәкаләтле заты, Идарәнең вазыйфаи заты тәкъдимнәре нигезендә әлеге Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр булганда кабул итә.

3.5. Кисәтүне төзү һәм җибәрү Идарәнең вазыйфаи заты, әлеге Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне алган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, гамәлгә ашыра.

3.6. Кисәтүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Идарәнең атамасы;

б) кисәтү датасы һәм номеры;

в) юридик зат атамасы, индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

г) мәҗбүри таләпләрне, норматив хокукый актларны күрсәтү, аларның мәҗбүри таләпләрне күз алдында тотучы структур берәмлекләрен кертеп;

д) юридик затның, индивидуаль эшкуарның нинди гамәлләре (гамәл кылмавы) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерү һәм китерергә мөмкин булу турында мәгълүмат;

е) юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрү буенча тәкъдим;

ж) юридик затка, индивидуаль эшкуарга кисәтүне үтәүләре турында Идарәгә хәбәрнамә җибәрү турында тәкъдим;

з) юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан кисәтүне үтәү турында хәбәрнамә җибәрү өчен срок (кисәтүне җибәргән көннән соң кимендә 6 0 календарь көн);

и) Идарәнең контакт белешмәләре, почта адресын һәм электрон почтасы адресын, шулай ук каршылыклар бирүнең, кисәтүне үтәү турында хәбәр итүнең башка мөмкин алымнарын күрсәтеп.

3.7. Кисәтүдә юридик затның, индивидуаль эшкуарның белешмәләр һәм документлар тапшыруы турындагы таләбе булырга тиеш түгел.

3.8. Кисәтү кәгазьдә килеш, тапшырылуы турында хәбәрнамәсе белән бергә, заказлы почта юлламасы рәвешендә йә юридик зат, индивидуаль эшкуар өчен мөмкин булган бүтән юл белән җибәрелә, моңа әлеге Административ регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән кисәтүне җибәрү турында карар кабул иткән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, шул исәптән юридик затның, индивидуаль эшкуарның Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән электрон почтасы адресына җибәрү йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның рәсми сайтында Россия Федерациясе законнары нигезендә урнаштырылуы мәҗбүри булган мәгълүмат составында күрсәтелгән адресына, йә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрү дә керә.

3.9. Кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча юридик зат, индивидуаль эшкуар Идарәгә үз каршылыкларын бирә ала.

3.10. Каршылыкларда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) юридик зат атамасы, индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

б) салым түләүченең – юридик затның, индивидуаль эшкуарның идентификацион номеры;

в) юридик зат, индивидуаль эшкуар адресына җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

г) кисәтүдә юридик затның, индивидуаль эшкуарның мәҗбүри таләпләрне бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата позицияне нигезләү.

3.11. Каршылыклар юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан Идарәгә кәгазьдә килеш, тапшырылуы турында хәбәрнамәсе белән бергә, заказлы почта юлламасы рәвешендә йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның, юридик зат исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә Идарәнең кисәтүдә күрсәтелгән электрон почтасы адресына, йә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән алымнар белән җибәрелә.

3.12. Идарә каршылыкларны карый, карау нәтиҗәләре буенча юридик затка, индивидуаль эшкуарга каршылыкларны алган көннән 20 көн эчендә әлеге Административ регламентның 3.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрә. Каршылыкларны карау нәтиҗәләре Идарә тарафыннан

мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалау чараларын оештыру һәм уздыру максатларында һәм юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган максатларда файдаланыла.

3.13. Каршылыклар булмаганда юридик зат, индивидуаль эшкуар кисәтүдә күрсәтелгән срокта Идарәгә кисәтүне үтәү турында хәбәрнамә җибәрә.

3.14. Кисәтүне үтәү турындагы хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) юридик зат атамасы, индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

б) салым түләүченең – юридик затның, индивидуаль эшкуарның идентификацион номеры;

в) юридик зат, индивидуаль эшкуар адресына җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

г) кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмәләр.

3.15. Хәбәрнамә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан Идарәгә кәгазьдә килеш, тапшырылуы турында хәбәрнамәсе белән бергә, заказлы почта юлламасы рәвешендә йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның, юридик зат исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә Идарәнең кисәтүдә күрсәтелгән электрон почтасы адресына, йә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән алымнар белән җибәрелә.

4 бүлекнең 2 таблицасында:

«Тикшерү уздыру өчен тапшырыла торган документ» графасының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Юридик затның гамәлгә кую документлары»;

«Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт» графасының 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзйөрешле машиналар һәм башка төрдәге техника паспорты турында» 26.06.1995 № 318 Россия Федерациясе Дәүләт стандартлары комитеты тарафыннан расланган нигезләмә, «Үзйөрешле машиналар һәм башка төрдәге техника паспорты турында» Евразия икътисадый комиссиясе коллегиясенең 18.08.2015 № 100 карары белән расланган»;

«Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт» графасының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тракторларны, үзйөрешле юллар салу һәм бүтән машиналарны һәм аларның тагылмаларын Россия Федерациясендә дәүләт теркәвенә алу буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 16.01.19951993 боерыгы белән расланган кагыйдәләре»;

6 пунктны төшереп калдырырга;

5 бүлектә:

5.3 бүлекчәдә:

5.3.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3.4. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы планлы күчмә тикшерү уздыруны башлау турындагы боерык күчермәсен юридик затка, индивидуаль эшкуарга планлы күчмә тикшерү уздыру хакындагы боерык күчермәсен, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, юридик затның, индивидуаль эшкуарның Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән электрон почтасы адресына җибәрә йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның рәсми сайтында күрсәтелгән булса йә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан элегрәк тәкъдим ителгән адресына бүтән мөмкин ысул белән җибәрә.»;

5.3.5 пунктның беренче абзацына: «, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, юридик затның, индивидуаль эшкуарның Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән электрон почтасы адресына җибәрә йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның рәсми сайтында күрсәтелгән булса йә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан элегрәк тәкъдим ителгән адресына» сүзләрен өстәргә:

5.4 бүлектә:

5.4.3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кирәк чакта Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән түбәндәге документларны һәм мәгълүматны әлеге Административ регламентның 1.5.1 пунктчасындагы тугызынчы һәм унынчы абзацлары таләпләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә соратып ала, шул исәптән электрон рәвештә дә:»;

түбәндәге эчтәлекле өченче-алтынчы абзацлар өстәргә:

«Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр;

индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр;

моннан алдагы календарь ел эчендә хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саны турындагы белешмәләр;

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.4.10 пункт өстәргә:

«5.4.10. Индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яисә бүтән вазыйфаи заты булмауга бәйле рәвештә йә юридик зат, индивидуаль эшкуар фактта эшчәнлек алып бармауга бәйле рәвештә, йә индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик затның җитәкчесенең яисә бүтән вазыйфаи затының тикшерү уздыру мөмкинлеген булдырмауга китерүче бүтән гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү уздыру мөмкин булмаган очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи, анда тикшерүне уздыру мөмкин

булмауның сәбәпләре күрсәтелә. Бу очракта Идарә тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән соң өч ай эчендә мондый юридик затка, индивидуаль эшкуарга карата планлы һәм күчмә планнан тыш тикшерү уздыру турында, планлы тикшерү уздыруны планлы тикшерүләрнең еллык планына кертмичә генә һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр итмичә генә, карар кабул итәргә хокуклы.»;

5.5 бүлекчәдә:

5.5.4 – 5.5.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5.4. Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, мәҗбүри таләпләрне бозуны ачыклау нигез булса, мондый бозуларны кылу мизгеленә кичектергесез чаралар күрү кирәклегенә бәйле рәвештә Идарә, тикшереп тору чаралары күрү турында прокуратура органнарына Идарәнең аны уздыру өчен нигез булган кирәкле документларын (планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында гаризаны, аңа башлык (башлык урынбасары) боерыгының күчермәсен кушып), Идарәнең планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турындагы документларын җибәрү юлы белән егерме дүрт сәгать эчендә хәбәр итеп, Идарә кичекмәстән планнан тыш күчмә тикшерү уздырырыга керешергә хокуклы. Бу очракта прокурор яисә аның урынбасары тиешле документлар кергән көннән планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул итә.

5.5.5. Тикшерү уздыру барышында Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыкта күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыра.

5.5.6. Тикшерү уздыру срогы әлеге Административ регламентның 2.3 пункты таләпләренә туры килергә тиеш.

5.5.7. Административ процедураны башкару нәтиҗәсе планнан тыш күчмә тикшерү белән каралган барлык тикшереп тору гамәлләрен башкару була.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.5.8 пунктлар өстәргә:

«5.5.8. Индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яисә бүтән вазыйфаи заты булмауга бәйле рәвештә йә юридик зат, индивидуаль эшкуар фактта эшчәнлек алып бармауга бәйле рәвештә, йә индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик затның җитәкчесенең яисә бүтән вазыйфаи затының тикшерү уздыру мөмкинлеген булдырмауга китерүче бүтән гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә планлы һәм күчмә планнан тыш тикшерү уздыру мөмкин булмаган очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи, анда тикшерүне уздыру мөмкин булмауның сәбәпләре күрсәтелә. Бу очракта Идарә тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән соң өч ай эчендә мондый

юридик затка, индивидуаль эшкуарга карата планлы һәм күчмә планнан тыш тикшерү уздыру турында, планлы тикшерү уздыруны планлы тикшерүләрнең еллык планына кертмичә генә һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр итмичә генә, карар кабул итәргә хокуклы.».

2. Әлеге боерык, 2017 елның 1 июлендә үз көченә керүче утыз тугызынчы абзацыннан гайре, басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р. Зыятдинов